**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Иске Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2026 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пунктында
үзара салым кертү турында

16 октябрь 2025 ел № 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш

Алынган чараларны түбәндәгеләргә җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Иске Кади торак пунктында трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, Иске Кади торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) йорт номерлары һәм урам исемнәре язылган элмә такталар әзерләү һәм урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә**

**ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру, Иске Кади торак пунктында урамнарны яктырту өчен кулланыла торган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү.

**- урамнарны яктырту җайланмасы** (Иске Кади авылының Тукай урамында урам яктырткычлары кую, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләргә түләү)

**- янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары төзү, ремонтлау** (Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкларга янгынга каршы керү юлларын торгызу);

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы Н.В.Мөктәсимов